ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020

# Тарих дәвамчылары

## Татарстан һәм татар халкы тарихына карата уен-бәйге

Автор: Т.Д.Насибуллина, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Җиһан» Балалар иҗат үзәге» өстәмә белем бирү педагогы, “Мәмәшир урта мәктәбе” тарих укытучысы.

Т.Д.Насибуллина.Тарих дәвамчылары. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Җиһан» Балалар иҗат үзәге», Кукмара, 2020 ел, 14 бит.

Ярдәмлек сыйныф җитәкчеләре, тәрбия эше буенча директор урынбасарлары, түгәрәк җитәкчеләре, предмет укытучылары өчен дә кирәкле әсбап булып торачак.

**Тема: Тарих дәвамчылары**

**Форма:** уен-бәйге

**Максаты:** укучыларда гражданлык-патриотик хисләр тәрбияләү, Татарстанның тарихы һәм мәдәни традицияләре турында белемнәрне киңәйтү.

**Бурычлар:**

- Танып белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү;
- Үз халкына, тарихына, гореф – гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту;
- Милләтебезнең гасырлар буена тупланган әдәп-әхлак нормаларын булдыру;

Халык - кешеләрнең тел, территориаль, экономик һәм мәдәни уртаклыгы ул. Аны кабиләчелектән соң һәм милләт барлыкка килгәнче чордагы этник берлек дип карау гадәткә кергән. Татар халкы оешкан чор, Евразиянең урта киңлегендә яшәүче башка күп кенә халыклардагы кебек үк, феодализм дәверенең нык үскән, җитлеккән урта гасырларына туры килә. Монда Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыклары җирлек ролен үти. Татарларның күпчелеге дөньядагы өч иң зур диннең берсе булган ислам динен тотучылар булып санала. Ул X гасыр башында ук, 922 елда, Идел Болгарында рәсми дин төсендә кабул ителә.

Татар халкы тарихы азатлык, бәхет өчен һәм илнең чәчәк атуы өчен аяусыз көрәшкән һәм якты исем калдырган батыр шәхесләргә бай. Алар - зур дәүләт, сәяси һәм гаскәри эшлеклеләре, милли-азатлык хәрәкәте юлбашчылары һәм атаклы галим-мәгърифәтчеләре: Идегәй һәм Чура батыр, Ибраһим һәм Сафагәрәй ханнар, Нурсолтан һәм Сөембикә ханбикәләр, Булат һәм Нурали Шириннәр, Шиһабетдин Мәрҗаниләр һәм башка фидакарь затлар.

Татар халкының, аерып әйткәндә Казан татарларының, хәзерге вакыттагы милли дәүләт формасы булып Татарстан Республикасы тора. Ул 1920 елда Татарстан АССР буларак төзелә. 1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты игълан ителде, ә 1991 елның 12 июнендә Татарстан Республикасының беренче Президенты сайланды. 1992 елның 6 ноябрендә ТР Югары Советы Татарстан Республикасының Конституциясен кабул итте, анда Татарстан халыкара хокуклы субъект дип игълан ителде.

Татар халкы тамырлары ерак гасырларга барып тоташа торган бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия. Безнең халык үзенең күп гасырлы әдәбияте, сәнгате һәм мәдәниятенең башка тармаклары тарихы белән хаклы рәвештә горурлана ала. Бу тарих кешелек мәдәниятенә Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Дәрдемәнд һ.б. якты талантларны бирде.

Шулай итеп, кадерле укучылар, татар халкының һәм Татарстанның борынгы һәм урта гасырлар тарихына - ифрат катлаулы, әмма бик бай һәм гаҗәеп кызыклы тарихи сәхифәләре эченә тирәнрәк керү өчен хәерле юл телибез сезгә!

**Уен барышы:**

Төркемнәргә биремнәр (3 төркемгә исәпләнелә)

**1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы туграалары турында беләсезме?**

1) РФ гербында ничә таҗ сурәтләнгән?
2) Татарстан Республикасы гербында барс кайсы тәпиен күтәргән?
3) Россия Федерациясе гербында ничә җан иясе күреп була?
4) Татарстан Республикасы гербында ничә чәчәк бар дип уйлыйсыз?
5) Татарстан Республикасы гербы формасы нәрсәне аңлата?
6) Кукмара районы гербында ничә тау сурәтләнгән?
7) Кайсы гербта герб иясенең исеме язылган?

Җаваплар:

1) 3
2) уң
3) 4
4) 2
5) кояш
6) 3
7) Татарстан


**2. Мин кайда идарә иттем?**

Сезгә ханнар исемнәре бирелә. Шуларны кайсы ханлыкта идарә итүләренә карап, бүлеп урнаштырыгыз.

| Идел Болгары | Алтын Урда | Казан ханлыгы |
|---|---|---|
| Алмыш | Батый<br>Мәнгү-Тимер<br>Үзбәк | Мәхмүд<br>Сафагәрәй<br>Мөхәммәт Әмин |

1) Сафагәрәй
2) Алмыш
3) Мәхмүд
4) Мәнгү-Тимер
5) Батый
6) Мөхәммәт Әмин
7) Үзбәк

### 3. Рәсемнәрдә нәрсә сурәтләнгән?





### 4. Өзекне укып, төшеп калган сүзләрне куегыз

Болгарның данын_______________ дә үстереп торган. Алар шәһәр базарларына да, елга ике мәртәбә уздырыла торган халыкара _________________ дә йөргәннәр. _____________ күп һәм төрле булуы аркасында базарлар кайнап торган. Сугышчылар үзләренә ______һәм __________ караганнар. Ювелирлар ____________ ясау өчен Балтыйк буеннан китерелгән гәрәбә сайлаганнар, тире осталары ____________ тиресе эзләгәннәр. Байлар мех, әрмән ________________ сайлаган, аерым товар исәбенә “җанлы корал”-______________ кергән.

Болгарның данын сәүдәгәрләр дә үстереп торган. Алар шәһәр базарларына да, елга ике мәртәбә уздырыла торган халыкара ярминкәләргә дә йөргәннәр. Товарларның күп һәм төрле булуы аркасында базарлар кайнап торган. Сугышчылар үзләренә кылыч һәм көбә күлмәк караганнар. Ювелирлар бизәнү әйберләре ясау өчен Балтыйк буеннан китерелгән гәрәбә сайлаганнар, тире осталары кәҗә тиресе эзләгәннәр. Байлар мех, әрмән келәмнәре сайлаган, аерым товар исәбенә коллар кергән.

### 5. Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән?


1. 
2. 
3. 

**6. Кайсы шәһәр турында?**

Өзекне укып, кайсы шәһәр турында сүз барганын белергә һәм шул шәһәрнең исемен язарга кирәк

1. ................-бөтен урта гасыр Европасында иң эре шәһәр. Үзенең территориясе буенча ул Париждан бер ярым тапкыр һәм Киев белән Римнан ике мәртәбә зуррак булган. Рус елъязмачылары аны Олуг шәһәр дип атыйлар. Хәзер республикабызның Спас районына карый. (Биләр)
2. ................да кирпеч йортлар шактый күп булган. Шундый йорт калдыкларының берсен археологлар шәһәр үзәгендә казып чыгардылар. Ул гөмбәз сыман түбәле ике катлы йорт булган. Кояш нурлары йорт эченә саргылт-яшел төстәге түгәрәк пыяла аша төшкән. Мичтән чыккан җылы һава йөрсен өчен, идән астына торбалар салып калдырылган. Башкаладан кала икенче бер зур шәһәр булган. (Суар)
3. X-XI гасырлар чигендә Идел һәм Казансу елгалары кушылган урыннан ерак түгел ................... дигән атама алып, кечерәк кенә кирмән үсеп чыга. Тиздән ул иң эре халыкара сәүдә үзәкләренең берсенә әверелә. Табылдыкларга караганда, ул Көнбатыш Европа, Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләре, Киев Русе белән сәүдә иткән. (Казан)

**7. Бу кайсы дәүләт сугышчысы?**

1. 
2. 
3. 

1-Алтын урда
2-Болгар
3-Казан ханлыгы

**8. Ышанам, ышанмыйм**

**Бирелгән җөмләләр дөресме, әллә юкмы, ничек уйлыйсыз?**

1) Казан ханлыгының башкаласы Мәскәү булган. юк
2) Кирмән диварлары тал бүрәнәләрдән торгызылган. юк
3) Казанның иң матур һәм иң ныгытылган уртадагы өлеше бистә дип аталган. юк
4) Бишбалта бистәсендә балта осталары яшәгән. эйе
5) Хан сарае янында ак таштан Нурсолтан мәчете гүзәллеге белән аерылып торган. юк
6) Болак буенда иртәдән кичкә кадәр Көрәеш ярминкәсе гөрләгән. юк
7) Хан сараена башня аша гына кереп булган. эйе
8) “Туп сарае” дигән җирдә уен кораллары сакланган. юк

**9. Кем турында сүз бара?**

1. М.Җәлил
1) Мостафа авылы.
2) Шагыйрь.
3) Моабит дәфтәрләре

2. Кол Гали
1) Болгар дәүләте.
2) Шагыйрь.
3) “Кыйссаи Йосыф”.

3. Аттила
1) Һуннар.
2) Татар Сөнчәлесе.
3) 453 ел.

4. Г.Тукай
1) Печән базары.
2) Шагыйрь.
3) “Су анасы”.

**10. Ребусны чишегез**




**11. Квест-уен** (Шул дөрес җавап санынча сүзләрнең хәрефләре ачыла)

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Кукмара атамасында ничә мари телгә алына? | 2 |
| 2 | Татар халкы ничә кат үлчәргә куша? | 7 |
| 3 | ТАССР ничә ел элек төзелә? | 100 |
| 4 | Сөембикә манарасы ничә катлы? | 7 |
| 5 | Кукмара районы ничә ел элек оешкан? | 90 |
| 6 | Кукмара районыннан ничә Советлар Союзы Герое чыккан? | 4 |
| 7 | Быел Бөек Җиңүнең ничә еллыгы билгеләп үтелә? | 75 |
| 8 | Мәмәшир авылына ничә кеше нигез салган дип санала? | 3 |

Сүзләр-исемнәр:

1) Колшәриф
2) Сөембикә
3) Туктамыш

# Биремнәргә күрсәтмә материаллар

1

## Тугралырыбызны беләсеңме?

1. Россия Федерациясе туграсында ничә таҗ бар?
2. Татарстан туграсында барс кайсы тәпиен күтәргән?
3. Россия туграсында ничә җан иясе күреп була?
4. Татарстан туграсында ничә чәчәк бар?
5. Татарстан туграсы формасы нәрсәне аңлата?
6. Кукмара районы туграсында ничә тау сурәтләнгән?
7. Кайсы туграда герб иясенең исеме язылган?




3
Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән?
1
2
3
Казанны алу
Болгарның монголлар тарафыннан алынуы
Ислам динен кабул итү


5
Рәсемнәр нәрсә аңлата?
1
3
2
Балта
Ук ату җайланмасы
Йозак

7

## Кайсы дәүләтнеке?




Алтын Урда сугышчысы




Болгар сугышчысы




Казан сугышчысы

8


## Ышанам...ышанмыйм...?

1. Казан ханлыгының башкаласы Мәскәү булган.
2. Кирмән диварлары тал бүрәнәләрдән торгызылган.
3. Казанның иң матур һәм иң ныгытылган уртадагы өлеше бистә дип аталган.
4. Бишбалта бистәсендә балта осталары яшәгән.
5. Хан сарае янында ак таштан Нурсолтан мәчете гүзәллеге белән аерылып торган.
6. Болак буенда иртәдән кичкә кадәр Көрәеш ярминкәсе гөрләгән.
7. Хан сараена башня аша гына кереп булган.
8. “Туп сарае” дигән җирдә уен кораллары сакланган.


9
Кем турында сүз бара?
1.Мостафа авылы.
2.Шагыйрь.
3.Моабит дәфтәрләре.


9
Кем турында сүз бара?
1.Болгар дәүләте.
2.Шагыйрь.
3.“Кыйссаи Йосыф”.


9
Кем турында сүз бара?
1.Һуннар.
2.Татар Сөнчәлесе.
3.453 ел.
ATTİLA


9
Кем турында сүз бара?
1.Печән базары.
2.Шагыйрь.
3.“Су анасы”.


11
Мине таны
1
Сөембикә
2
Колшәриф
3
Туктамыш